ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Береговая, д.30, с. Соболевское, 422595

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яр ур., 30 нчы йорт, Соболевский авылы, 422595

Тел.: (84379) 35-7-22, факс: (84379) 35-7-22.

____________________№__________________

На №________________от__________________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Чулпаниха авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Сез Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Чулпаниха авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?-1) Чулпаниха авылының торак пункты территориясендә юлларны ремонтлау өчен, товарны китерү өчен билгеләнгән пунктка кадәр илтеп җиткерүче хисабына вак таш сатып алу, дигән сорау буенча 2022 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 56 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 33 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен 29 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Чулпаниха авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. «Сез Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Чулпаниха авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (ташламалы категорияләрдән тыш) 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?-1) Чулпаниха авылының торак пункты территориясендә юлларны ремонтлау өчен, товарны китерү

өчен билгеләнгән пунктка кадәр илтеп җиткерүче хисабына вак таш сатып алу, дигән кабул ителгән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Чулпаниха авылы гражданнары җыенының нәтиҗәләрен Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________________ О.Н.Майорова